РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Асеевского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района
ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әсәй авыл җирлеге
Башлыгы
Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай
районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2020 ел № 5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының 22.04.2012 ел № 39 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башлыгы тора.
3. Билгеләргә:
- үткәрү вакыты-2020 елның 30 ноябре 16.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны- Әсәй авыл мәдәният йорты;
- тикшерелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Әсәй авылы, Үзәк урам, 38Б йорт.
4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Интернет мәгълүматтелекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru. адресы буенча 2020 елның 11 ноябреннән дә соңга калмыйча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам

Башлык: З.Ә. Идрисов.